КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 август г.Казань № 638

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 декабрь, 1161 нче карары белән расланган Юридик затларның Татарстан Республикасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 1 декабрь, 1161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 август, 826 нчы, 2022 ел, 17 декабрь, 1364 нче, 2023 ел, 20 апрель, 512 нче, 2024 ел, 27 декабрь, 1224 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның Татарстан Республикасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 13 пунктның беренче абзацында «ике чара» сүзләрен «бер чара» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-Министры А.В.Песошин